КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 7 май г.Казань № 327

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән – архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03<*>)».

4.3 нче пунктка түбәндәге пунктчалар өстәргә:

«4.3.8. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә төзергә, реконструкцияләргә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәтнамә бирү.

4.3.9. Төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләре чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектларын эксплуатацияләүгә кертүгә рөхсәтнамә бирү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин